**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево,
423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592)
7-20-31
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай**
**муниципаль районы**
**БАШЛЫГЫ**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай
шәһәре, 423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592) 7-
20-31
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«__19__» ____07_____ 2024 ел.** **№ __144___**

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районының
«Кәкре-Елга авыл җирлеге»
җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре
проекты буенча гавами тыңлауларны
билгеләү турында (үзгәрешләр кертү)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 31 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2018 елның 22 августындагы 203-30 номерлы карары белән расланган «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Кәкре-Елга авыл җирлеге» җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча (үзгәрешләр кертүне) (алга таба - гавами тыңлаулар) билгеләргә.

2. Билгеләргә:
- гавами тыңлауларны оештыручы - Азнакай муниципаль районының Кәкре-Елга авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гавами тыңлаулар уздыру вакыты - 18 календарь көн (2024 елның 22 июленнән 2024 елның 08 августына кадәр);
- 9 август көнне мәскәү вакыты буенча 16.00 сәгатьтә гавами тыңлаулар үткәрү датасы, вакыты һәм урыны: Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Кәкре-Елга авылы, Совет урамы, 23А йорт, Азнакай муниципаль районының Кәкре-Елга авыл җирлеге Башкарма комитеты,
- гавами тыңлауларны үткәрү формасы - җыелыш.

3. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2024 елның 22 июленнән 2024 елның 08 августына кадәр эш көннәрендә мәскәү вакыты буенча 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр түбәндәге адрес буенча язма рәвештә кабул ителә: 423320, Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Какре-Елга авылы, Совет урамы, 23А йорт, Азнакай муниципаль районы Кәкре-Елга авыл

җирлеге Башкарма комитеты яисә түбәндәге адрес буенча: 423330, Татарстан Республикасы, Азнакай шәһәре, М.Солтангалиев урамы, 24 йорт, Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге.

3. Азнакай муниципаль районының Кәкре-Елга авыл җирлеге Башкарма комитетына:

- гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән вакытта гавами тыңлауларны әзерләргә һәм уздырырга;

- җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты материалларын Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru;

- 2024 елның 22 июленнән 08 августына кадәр эш көннәрендә мәскәү вакыты буенча 8 сәгать 00 минуттан 17 сәгать 00 минутка кадәр Азнакай муниципаль районының Кәкре-Елга авыл җирлеге Башкарма комитетында түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Кәкре-Елга авылы, Совет ур., 23А йорт җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты материаллары экспозициясен оештырырга:

- гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләргә һәм рәсмиләштерергә;

- Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә: http://aznakaevo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Кәкре-Елга авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Кәкре-Елга авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен әзерләү буенча (үзгәрешләр кертү) эшче төркем составын кушымта нигезендә расларга.

5. Әлеге карарны Азнакай муниципаль районының Кәкре-Елга авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык М.З. Шәйдуллин

Азнакай муниципаль районы Башлыгы карарына кушымта
« ____»________ 2024 №_____

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Кәкре-Елга авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын тикшерү буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем составы (үзгәрешләр кертү)

*Эшче төркем рәисе:*

| | |
|---|---|
| Шәмсетдинов А.Х. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |

*Эшче төркем секретаре:*

| | |
|---|---|
| Әюпова Р.Р. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече (килешү буенча) |

*Эшче төркем әгъзалары:*

| | |
|---|---|
| Шәрәфетдинова С.Ф. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге җитәкчесе (килешү буенча) |
| Мөхәмәтҗанов И.М. | Азнакай муниципаль районының Кәкре-Елга авыл җирлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Сабирҗанов Н.Г. | Азнакай районы Советы авыл җирлекләре белән эшләү секторы мөдире |